Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Советы

Пановка авыл җирлеге башлыгы карары

8 сентябрь, 2023 ел № 3

Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Башлыгының 2016 елның 20 апрелендәге 1 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында аерым категория затларга счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата средстволарны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Таләпләрнең үтәлешен тикшерү» 2 өлешенең 2.12 пунктында «Әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктының 1 - 3 бүлекләрендә күрсәтелгән затлар тарафыннан туры килмәү» сүзләреннән соң «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев